ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«25» апреля 2023 ел № 96

«2019-2023 елларга Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 18 мартындагы 96 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль закон,«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының «Кече һәм урта эшкуарлыкка ярдәм итү буенча муниципаль программалар өстәү кирәклеге турында» 01.02.2023 елның 01-60/616 номерлы хатына таянып, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. «2019-2023 елларга Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 18 мартындагы 96 номерлы карарына беркетелгән үзгәрешләрне расларга.

2. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына әлеге карар буенча финанслауны бюджетның тиешле бүлекләрендә каралган акчалар чикләрендә тәэмин итәргә тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (https://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының икътисадый үсеш бүлеге башлыгы А.С. Заитовага йөкләргә.

**Җитәкчесе** **Л.Ф. Нургаянов**

Татарстан Республикасы Әгерҗе
муниципаль районы Башкарма
комитетынын 18.03.2020 елнын 96
номерлы карары белән расланды
(карар редакциясендә
25.04.2023 № 96)

**«2019-2023 елларга Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү» муниципаль программасы турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 18 мартындагы 96 номерлы карарына үзгәрешләр**

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы башкарма комитетының 2020 елның 18 мартындагы 96 номерлы карары белән расланган «2019-2023 елларга Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү» муниципаль программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Муниципаль программаның 3 өлешендәге 3.1 пунктындагы 3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Кече һәм урта эшкуарлык субъектларына адреслы финанс һәм мөлкәти ярдәм чараларын гамәлгә ашыру һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектларына, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районына ярдәм итү инфраструктурасы оешмалары, шул исәптән Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының төрле программаларында катнашучы социаль эшкуарлыкка керүчеләр»